**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Учаллинского сельского**
**поселения Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Советская, д. 51, село Учалле,
Азнакаевского муниципального
района, 423317

**ТАТАРСТАН**
**РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**

Совет урамы, 51, Үчәлле авылы
Азнакай муниципаль районы
423317

Тел./факс(885592)36-8-32; E-mail:Uchal.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 гыйнвар 2022ел №5

2022 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенең иң чик хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә, 2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлегенең иң чик күләмен 6964(алты мең тугыз йөз алтмыш дүрт сум) 68 тиен итеп билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Г.М.Төхвәтуллина

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге карарына
1 нче кушымта
«28» гыйнвар 2022 №5

2022 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
«Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча гарантияле хезмәтләр хакының чик күләме

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең хакы, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 4507,21 |
| 2 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 1121,35 |
| 3 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1336,12 |
| **4** | **Барлыгы** | **6964,68** |

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге карарына
1 нче кушымта
«28» гыйнвар 2022 №5

2022 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
«Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча гарантияле хезмәтләр хакының чик күләме

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең хакы, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Кәфенләү | 952,23 |
| 2 | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 3554,98 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 1121,35 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1336,12 |
| **5** | **Барлыгы** | **6964,68** |